КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 февраль г.Казань № 71

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 8 август, 640 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 8 август, 640 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 октябрь, 932 нче; 2020 ел, 30 гыйнвар, 49 нчы; 2021 ел, 30 октябрь, 1022 нче; 2023 ел, 31 май, 662 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы

дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Максатчан уку турында шартнамә төзергә теләүче граждан (граждан хезмәткәре) урта һөнәри яки югары белем бирүнең мәгариф программасы буенча укырга кергәндә яки турыдан-туры укыган вакытта максатчан уку турында шартнамә төзү конкурсында катнашу хакында заявка бирергә мөмкин. Укырга кергәндә әлеге заявка кәгазь рәвешендә яки электрон төрдә, ә укыган вакытта кәгазь рәвешендә тапшырыла.

Урта һөнәри яки югары белем бирүнең мәгариф программасы буенча укырга кергәндә яки укыган вакытта граждан (граждан хезмәткәре) оары бер дәүләт органы белән максатчан уку турында шартнамә төзергә хокуклы.»;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт органы «Работа в России» дигән эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада максатчан уку турында шартнамә яки шартнамәләр төзү турында тәкъдимнәр урнаштыра, әлеге тәкъдимнәрдә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясындагы 7 өлешендә каралган белешмә бирелергә тиеш.

Әлеге тәкъдимнәрне үз эченә алган мәгълүматтан, федераль законнар белән кулланылышы чикләнгән мәгълүматтан тыш, һәркем файдалана алырга мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән заявканы кәгазьдә тапшырганда граждан (граждан хезмәткәре) дәүләт органнары тарафыннан «Работа в России» дигән эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформада урнаштырылган максатчан уку турында шартнамә яки шартнамәләр төзү турындагы тәкъдимнәр белән мөстәкыйль таныша һәм турыдан-туры дәүләт органына яки максатчан уку урнаштырылырга тиешле белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага мөрәҗәгать итә. Электрон рәвештә әлеге гариза укырга кабул итү турындагы гариза белән бергә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша тапшырыла. Граждан (граждан хезмәткәре) үзенең дәүләт органы тарафыннан максатчан уку турында шартнамә төзелә торган гражданга (граждан хезмәткәренә) карата куела торган таләпләргә туры килүен раслый торган торган мәгълүмат бирә.»;

26 пунктта:

беренче абзацта «каралган» сүзе алдына «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясындагы 3, 5 өлешләрендә» сүзләрен өстәргә;

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) уку чорында конкурс үткәргән дәүләт органы тарафыннан конкурс йомгаклары буенча максатчан уку турында шартнамә төзегән гражданга (граждан хезмәткәренә) акча түләнә (алга таба – өстәмә түләү). Югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучылар өчен өстәмә түләү күләме югары белем бирелә торган дәүләт мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы

студентлар өчен билгеләнгән дәүләт академик стипендиясеннән түбән булмаган күләмдә тәшкил итә. Урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучылар өчен өстәмә түләү күләме дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы студентлар өчен билгеләнгән дәүләт академик стипендиясенең 50 процентын тәшкил итә;»;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) граждан (граждан хезмәткәре) белән максатчан уку турында шартнамә төзегән дәүләт органы яисә аның территориаль органы граждан (граждан хезмәткәре) укып бетергәннән соң аның белән сроклы хезмәт контракты (алга таба – сроклы хезмәт контракты) төзи; әлеге контрактта гражданның (граждан хезмәткәренең) максатчан уку турындагы шартнамәдә билгеләнгән дәүләт органында яисә аның территориаль органында кимендә өч ел һәм иң күбе биш ел граждан хезмәте үтү, шулай ук укып бетергәннән соң граждан (граждан хезмәткәре) билгеләнәчәк дәүләт граждан вазыйфасын кимендә бер ел, әмма максатчан уку турында шартнамәдә билгеләнгән эшкә урнашу срогыннан соңка калмыйча биләү йөкләмәсе карала.»;

29 пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасы өстәргә:

«г) гражданның (дәүләт хезмәткәренең) өлгерешенә карата дәүләт органының таләпләре һәм бу таләпләр граждан (дәүләт хезмәткәре) тарафыннан үтәлмәгәндә дәүләт органы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 26 пунктында күрсәтелгән ярдәм чаралары кыскартылу мөмкинлеге.».

2. Бу карар 2024 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин